# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында граждfestнар җыены нәтиҗәләре турында

**от 27.10. 2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 27 октябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2020 елның 27 октябрендә 11 сәгать 00 минутта һәм 2020 елның 27 октябрендә 12 сәгать 00 минутта этаплап уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Исәнбай авылы территориясендә су насослары, колонкалар, сантехник материаллар, су үткәргечен алыштыру өчен полиэтилен торбалар һәм краннар сатып алу;

- Лампаларга, дроссельләргә, фонарьларга хезмәт күрсәтү, ремонт ясау һәм алыштыру, Исәнбай авылында урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу;

- Исәнбай авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

- Бима елгасы аша Исәнбай авылы күперен ремонтлау, төзелеш материаллары сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү);

- Исәнбай авылының Совет, Октябрь урамнарын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

- МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу (төягеч, ротор чапкычы, трактор арбасы);

- Исәнбай авылында чишмәләр территориясен төзекләндерү;

- Кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кисү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 618 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 339 кеше, бу 54,8 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 339 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Исәнбай авылы территориясендә су насослары, колонкалар, сантехник материаллар, су үткәргечен алыштыру өчен полиэтилен торбалар һәм краннар сатып алу;

- Лампаларга, дроссельләргә, фонарьларга хезмәт күрсәтү, ремонт ясау һәм алыштыру, Исәнбай авылында урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу;

- Исәнбай авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу);

- Бима елгасы аша Исәнбай авылы күперен ремонтлау, төзелеш материаллары сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү);

- Исәнбай авылының Совет, Октябрь урамнарын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

- МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу (төягеч, ротор чапкычы, трактор арбасы);

- Исәнбай авылында чишмәләр территориясен төзекләндерү;

- Кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кисү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф. СИРАЕВ